| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.11.2022 Казан ш. № 527-19/э-2022

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының аерым карарларын гамәлдән чыккан дип тану турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр энергетикасында җайга салынулы бәяләр (тарифлар) өлкәсендә бәяләр кую турында» 2011 елның 29 декабрендәге 1178 номерлы, «Электр челтәре хуҗалыгы объектлары хуҗаларын челтәр оешмаларына кертү турында» 2015 елның 28 февралендәге 184 номерлы карарлары, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 2022 елның 17 ноябрендәге 38-ПР утырыш беркетмәсе нигезендә, «Газпром энерго» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең Урал яны филиалы тарафыннан Татарстан Республикасы территориясендә электр энергиясен тапшыру буенча хезмәтләр күрсәтү буенча җайга салынулы эшчәнлек төрен гамәлгә ашыруны туктатуга бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының түбәндәге карарларын үз көчен югалткан дип танырга:

«Газпром энерго» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең Урал яны филиалы һәм «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен 2021-2025 елларга электр энергиясе тапшыру хезмәте күрсәтүгә аерым тарифлар билгеләү турында» 11.12.2020 № 394-10/э-2020;

«Газпром энерго» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең Урал яны филиалы белән «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясе тапшыру хезмәтләренә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 11.12.2020 № 394-10/э-2020 карары белән билгеләнгән озак сроклы аерым тарифларга 2022 ел өчен төзәтмә кертү хакында» 01.12.2021 № 403-15/э-2021.

2. Әлеге карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев